ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ КАРАР ______________

с. Верхний Услон

Югары Ослан муниципаль районының
«Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе»
муниципаль бюджет гомуми белем бирү
учреждениесенең филиалы – «Мәмәтхуҗа
башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе»н
бетерү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 61-63 статьялары, «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәве турында» 2001 елның 08 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы муниципаль берәмлеге уставы нигезендә бюджет акчаларын тотуны оптимальләштерү, матди-техник ресурслардан нәтиҗәле файдалану һәм мәгариф учреждениесенә идарә итүнең оптималь системасын булдыру максатларында, 2020 елның 7 апрелендәге Югары Ослан муниципаль районының Иске Рус Мәмәтхуҗасы һәм Татар Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең гражданнар җыены беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан районы, Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы, Центральная урамы, 5 йорт адресы буенча урнашкан «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең филиалы – «Мәмәтхуҗа башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе»н бетерергә.

2. «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе директоры Панасик Николай Владимировичны салым органнарындагы хәбәрнамәләр һәм гаризалар формаларын дәүләт теркәвенә алганда гариза бирүче вәкаләтле итеп билгеләргә.

3. «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры Панасик Николай Владимировичка гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртип һәм сроклар нигезендә юкка чыгару чараларын үтәүне тәэмин итәргә:

– «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы» - «Мәмәтхуҗа башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе»н бетерү турында юридик затны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга әлеге карар кабул ителгән көннән өч көн эчендә, законда билгеләнгән тәртиптә, хәбәр итәргә.

4. «Мәмәтхуҗа башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» - «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы бетерелүгә бәйле рәвештә «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры Панасик Николай Владимировичка

«Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе В.С. Тимиряев

5 нөсхәдә
әзерләде һәм
бастырды:
В.В. Касимов